СОВЕТ ОМАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.18, с. Омары,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422183

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОМАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мәктәп ур., 18 нче йорт, Омар авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422183

тел.(факс): (85563) 2-82-47; e-mail:Omar.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение | Карар

15 августа 2022 г. | № 3-16

Керемнәр, милек һәм милек йөкләмәләре турында мәгълүмат тапшыру турында Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында_Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлегендә муниципаль вазыйфа яки контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында , шулай ук Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге Советының 2020 елның 19 февралендәге № 4-55 карары (13.04.2021 №1-7, от 10.06.2021 №2-8 карарлар редакциясендә) белән расланган контракт буенча муниципаль вазыйфаларны яисә җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү тәртибе турындагы Нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.3 пунктының 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлар), цифрлы финанс активлары, санлы валюта сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча үзенең, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр, әгәр дә мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-бирешне башкару алдыннан булган соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып китсә, һәм алыш-биреш башкарган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр.».

1.2. 2.4 пунктының 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлар), цифрлы финанс активлары, санлы валюта сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча үзенең, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр, әгәр дә мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-бирешне башкару алдыннан булган соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып китсә, һәм алыш-биреш башкарган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр.».

2. 2014 елның 19 ноябрендәге 6-15 номерлы Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге Советының (13.04.2016 №3-9, 29.07.2016 №3-12, 10.06.2021 №2-8 редакциядә) белән расланган Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакында нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

2.1. 6 пунктның «в» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлар), цифрлы финанс активлары, санлы валюта сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча үзенең, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр, әгәр дә мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-бирешне башкару алдыннан булган соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып китсә, һәм алыш-биреш башкарган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр.»;

3. «Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм массакүләм мәгълүмат чараларына «Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында", Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге Советының 2017 елның 25 августындагы 1-25номерлы карары (10.06.2021 ел, №2-8 редакциясендә) белән расланган (алга таба-Тәртип) түбәндәге үзгәреш кертергә:

3.1. Тәртипнең 3 пунктындагы «г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) җир кишәрлеген, күчемсез мөлкәтнең бүтән объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында

катнашу өлеше), санлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча алыш-биреш башкарылган акчаларны алу чыганаклары турындагы мәгълүматлар, әгәр дә мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче затның һәм аның хатынының (иренең) алыш-бирешне башкару алдыннан булган соңгы өч елдагы гомуми керемennән артып китсә, һәм алыш-биреш башкарган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр.».

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук рәсми http:// mamadysh.tatarstan.ru сайтка урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Башлык,
Мамадыш муниципаль районы
Омар авыл җирлеге Советы рәисе Л.Н.Хәбибуллин